РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТИХОНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423655 Менделеевский район, с. Тихоново,
ул. Шишкина д. 3А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТИХОНОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423655 Менделеевск районы,
Тихоново авылы, Шишкин урамы, 3А

тел./факс (85549)3-43-62 Email: Tihon.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ  КАРАР

2021 елның 12 апреленнән  № 27

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 25 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар турында белешмәләр бирү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тихоново авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Тихоново авыл җирлеге
Советы рәисе А.М. Карманов